Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Камы-Исмәгыйль авыл Советы

КАРАРЫ

Камы-Исмәгыйль 2026 ел №12

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Камы-Исмәгыйль авыл Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 104 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Камы-Исмәгыйль авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Камы-Исмәгыйль» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 31, 32 бүлекләре нигезендә,

Камы-Исмәгыйль авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Камы-Исмәгыйль авыл Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 104 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Камы-Исмәгыйль авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Камы-Исмәгыйль авыл Советының 2015 елның 05 маендагы 126, 2015 елның 29 октябрендәге 5, 2018 елның 20 августындагы 47, 2019 елның 06 мендагы 61, 2021 елның 02 августындагы 22 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктның 4.1 пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган салым салу объектлары, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш;»;

1.2. 3 пунктның 3.1, 3.2 пунтчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. өч һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган физик затлар (мәгариф оешмаларында көндезге бүлектә белем алучы 23 яшькә кадәрге балалар);

3.2. мәгариф оешмаларында көндезге бүлектә белем алучы балигъ булмаган балалар һәм 23 яшькә кадәрге балалар, әлеге пунктның 3.1 бүлегендә күрсәтелгән физик затлар;».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында, Камы-Исмәгыйль авылы, Ленин урамы, 92а йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтындана урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Камы-Исмәгыйль авыл
җирлеге башлыгы

А.З.Шайдуллина